| | |
|---|---|
| **ГЛАВА БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

22.11.2019 е. Олы Подберезье ав. № 6

2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлаулары уздыру турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «2020 елга һәм 2021-2022 елларга план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге бюджеты проекты турында» карар буенча фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 13 ноябрендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында халыкка игълан ителгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советының «2020 елга һәм 2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге бюджеты проекты турында» карары буенча халык тыңлаулары уздырырга.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүматый стендларында һәм рәсми сайтында 2019 елның 23 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Билгеләргә:

халык тыңлаулары уздыру вакыты- 30.11.2019 10.00 сәг;

уздыру срогы – 1 көн;

уздыру урыны – ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье ав., Ирек Мәйданы урамы, 31 й. (авыл мәдәният йорты бинасы);

халык тыңлауларында фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, чыгыш ясап катнашуга заявкалар бирелергә мөмкин адрес: ТР, Кайбыч районы, Олы Подберезье ав., Ирек Мәйданы урамы, 31 й.( эш көннәрендә - 8.00 - 17.00 сәг кадәр).

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Башкарма комитетына 2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Подберезье авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм уздырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы Ф.А. Чекмарев